# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Загорье торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**01 ноябрь 2024 ел.** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Загорье торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Загорье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 500 сум күләмендә үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Загорье торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Загорье торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3. Әлеге карарны Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Азнакай муниципаль районының
халык җыенында рәислек итүче,
Вахит авыл җирлегенең Башлыгы Г.И. Әскәрова